**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район
д. Тимофеевка, ул. Профсоюзная, 45

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Тимофеевка авылы, Профсоюз ур, 45

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail:Usad.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**
**14.10.2024 г.** — **№ 113**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегендә бюджет процессы турында» 2021 елның 23 сентябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 2024 елның 30 сентябрендәге 02-01-26 номерлы мәгълүматы нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлегендә бюджет процессы турында» 2021 елның 23 сентябрендәге 32 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге советы карары (2021 елның 13 декабрендәге 37 номерлы, 2024 елның 13 февралендәге 95 номерлы, 14.08.2024 елның 14 маендагы 112 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасына «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Усад авыл җирлеге Башлыгы — Р.Ф. Сибгатуллин